**ГЛАВА НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2026 ел, 23 гыйнвар № 3

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Пробация кулланыла торган затларның социаль тәртибен коррекцияләү, ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм тернәкләндерү, яңа җинаятьләр кылуны кисәтү мәсьәләләрен хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 29 июлендәге «Татарстан Республикасы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру хакында» 631 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составын 1 нче кушымта нигезендә төзергә һәм расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2019 елның 02 декабрендәге 77 номерлы;

«Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 05 мартындагы 16 номерлы;

«Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 23 мартындагы 19 номерлы;

«Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 16 февралендәге 7 номерлы;

«Ирекгән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 21 февралендәге 6 номерлы.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Е.А. Тарнавский

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2026 елның «23» гыйнварындагы
3 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия составы

Комиссия рәисе:

| | |
|---|---|
| Тарнавский Егор Александрович | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы |

Комиссия рәисе урынбасары:

| | |
|---|---|
| Бутина Анна Ивановна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

Комиссия секретаре:

| | |
|---|---|
| Завалишина Валерия Александровна | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты балигъ булмаганнар эшләре һәм административ практикасы буенча секторының баш белгече (балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең җаваплы секретаре) (килешү буенча) |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гурьева Наталья Николаевна | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Камалетдинов Дамир Рөстәм улы | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Митрясов Александр Николаевич | Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Рамазанова Гөлүсә Минхарис кызы | Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Яңа Чишмә районы буенча җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Роменская Наталья Александровна | «Яңа Чишмә район үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Фасахов Ринат Рифгать улы | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хлопунов Владимир Александрович | Россия ҖҮФХИнең ТР буенча идарәсе Чистай ФКУ (Яңа Чишмә районы буенча дислокация белән) өлкән инспекторы, эчке хезмәт өлкән лейтенанты (килешү буенча) |
| Хөснуллина Резеда Гайсә кызы | «Яңа Чишмә районы буенча Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2026 елның «23» гыйнварындагы
3 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба - ведомствоара комиссия) - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, гражданнар җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшчәнлек алып баручы башка оешмалар белән ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче даими эшләүче координация органы.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә 2023 елның 6 февралендә кабул ителгән 10-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль законына, башка федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бердәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

1.4. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге ресоциализацияләүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә ярдәм күрсәтү күздә тотылган затларның ихтыяр белдерү иреге һәм ихтыяр иреге принципларына нигезләнә.

## II. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында хөкем ителгәннәргә, җинаять-хокукый характердагы башка чаралар билгеләнгән

затларга һәм мәҗбүри эшләр яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән, авыр тормыш хәлендә калган затларга карата кулланыла торган чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән:

һөнәри юнәлеш һәм хезмәт адаптациясе;

торак һәм көнкүреш төзелеше;

медицина ярдәме;

белем алу;

социаль хезмәт күрсәтү хокукын гамәлгә ашыру;

психологик ярдәм;

юридик ярдәм;

югалган социаль элемтәләрне һәм функцияләрне торгызуга ярдәм итү;

пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерүнең, социаль адаптацияләүнең һәм социаль тернәкләндерүнең башка формалары.

2.2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, гражданнар җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән пробация кулланыла торган затларны ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген һәм эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итү.

2.3. Пробация кулланыла торган затларның бердәм реестрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Җинаять кылуны кабатлауны (рецидивны) профилактикалау.

2.5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү буенча үткәрелә торган эшләр турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү.

## III. Ведомствоара комиссиянең вәкаләтләре

Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында ведомствоара комиссия түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

3.1. Ресоциализацияләүдә, социаль адаптацияләүдә һәм социаль тернәкләндерүдә ярдәм күрсәтү турында гариза кергән затларның социаль хәлен индивидуаль тәртиптә карый һәм анализлый.

3.2. Конкрет затка карата, аның шәхесенең үзенчәлекләре һәм шәхси ихтыяҗларын исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль ярдәм механизмнары, башка оешмалар һәм гражданлык җәмгыяте институтлары мөмкинлекләрен күздә тотып, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясендә пробация турында» 2023 елның 6 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә пробация кулланыла торган затларны ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм социаль тернәкләндерү турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 350 номерлы боерыгы белән расланган формада индивидуаль ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль тернәкләндерү программасын (алга таба - индивидуаль программа) эшли. Тернәкләндерү программасында каралган чараларның һәркайсын гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларны, аларны гамәлгә ашыру срокларын билгели.

3.3. Ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль тернәкләндерү буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелеген анализлый.

3.4. Индивидуаль программаны гамәлгә ашыруны туктату турында карар кабул итә:

индивидуаль программада каралган чараларны тәмамлаганнан соң;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы чикләреннән даими яшәү урынына чыгу очрагында;

пробация кулланудан баш тарту турында гариза кергәндә;

ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль тернәкләндерүнең индивидуаль программасын алга таба гамәлгә ашыру мөмкинлеген чыгарып ташлаучы башка очракларда.

3.5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында кабат җинаять кылуны (рецидивны) профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.6. Ведомствоара комиссия хокуклы:

3.6.1. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм граждан җәмгыяте институтлары тарафыннан башкаруга тәкъдим ителгән карарларны кабул итәргә;

3.6.2. Җинаять яки административ җаваплылыкка китерә торган закон бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен хокук саклау органнарына тиешле документларны һәм материалларны җибәрергә.

3.7. Ведомствоара комиссия пробация өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен үз компетенциясе чикләрендә пробация субъектлары булган органнар, учреждениеләр һәм оешмалар белән хезмәттәшлек итә:

3.7.1. Россия Федерациясе җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (аның территориаль бүлекчәләре) белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

хөкем ителгәннәрне, җинаять-хокукый характердагы башка чаралар билгеләнгән затларны һәм мәҗбүри эшләр рәвешендәге яисә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән, авыр тормыш хәлендә калган затларны, пробация кулланыла торган затларның бердәм реестры операторы буларак исәпкә алу;

башкарма яки постпенитенциар пробация кулланыла торган затлар белән социаль һәм тәрбияви эш уздыру;

ресоциальләштерүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль тернәкләндерүгә шәхси мохтаҗлыкны бәяләүне уздыру;

башкарма яки постпенитенциар пробация куллану турында карарлар кабул ителгән затлар өчен индивидуаль программалар әзерләү;

пробация үзәге эшчәнлеген коммерциячел булмаган, шул исәптән дини, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан оештыру.

3.7.2. Эчке эшләр органнары белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

башкарма һәм постпенитенциар пробация куллану;

индивидуаль профилактик эш алып бару;

хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу;

хөкем ителүчене паспорт белән документлаштыру.

3.7.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләр (социаль яклау бүлекләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасының социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) тарафыннан түбәндәге мәсьәләләр буенча:

халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау (хезмәт күрсәтү) өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәүче яисә иректән мәхрүм итү рәвешендәге учреждениеләрдән азат ителгән һәм авыр тормыш хәлендә калган затларга социаль хезмәтләр күрсәтү һәм эшкә урнашырга ярдәм итү өлешендә;

мәҗбүри эшләр яисә ирегеннән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән һәм авыр тормыш хәлендә калган затларга карата эшкә урнашу һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлешендә статистик мәгълүматны исәпкә алу;

билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, социаль хезмәт алучы затлар белән профилактик эш алып бару;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче балигъ булмаганнарны, шулай ук ирегеннән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны социаль адаптацияләү;

булган буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар турында, хезмәт шартлары турында, хезмәт хакы турында һәм вакансияләр эзләүчеләргә карата квалификация таләпләре турында мәгълүмат бирү юлы белән пробация кулланыла торган затларны ресоциальләштерүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль тернәкләндерүгә ярдәм итү;

ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлау максатларында һөнәри ориентация буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган күрсәтелгән категориядәге затларга һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү;

эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, социаль адаптацияләү буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга эш бирүчеләрне кызыксындыру;

3.7.4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан беренчел медицина-санитария ярдәмен, профилактик һәм диспансер күзәтүен оештыру мәсьәләләре буенча;

3.7.5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гомуми белем, урта һөнәри белем алу, һөнәри белем алу мәсьәләләре буенча;

3.7.6. Татарстан Республикасы социаль фонды бүлекчәләре тарафыннан индивидуаль счет ачу һәм индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган һәм индивидуаль счет иминият номеры турында белешмәләр булган документны рәсмиләштерү мәсьәләләре буенча пенсия тәэминаты алуда (аны алу хокукы булган затлар өчен);

3.7.7. Дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары үз компетенцияләренә туры китереп.

## IV. Ведомствоара комиссияне формалаштыру тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

Ведомствоара комиссия рәисе:

Ведомствоара комиссия эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итә;

Ведомствоара комиссия утырышларын алып бара, хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия;

Ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында йөкләмәләр бирә;

Ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән документларга кул куя;

Ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Ведомствоара комиссия секретаре:

Ведомствоара комиссия рәисе күрсәтмәләрен үти;

Ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга ведомствоара комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җәза үтәү системасы учреждениеләре администрацияләреннән алынучы мәгълүматны җыя һәм гомумиләштерә, затны алда торган азат итү, аның торагы, эшкә сәләте һәм булган белгечлекләре булу турында мәгълүмат җыя;

ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан, ресоциальләштерүдә, социаль адаптациядә һәм социаль тернәкләндерүдә ярдәм күрсәтү турында гаризалар кабул итә;

ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль тернәкләндерү программасының һәр катнашучысына индивидуаль программа чараларын үтәү буенча документлар һәм белешмәләр кертелгән озата бару картасы һәм шәхси эш рәсмиләштерә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның Республика регистрының муниципаль сегментын алып бара;

муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документларны, материалларны һәм мәгълүматны соратып ала;

ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

Ведомствоара комиссия утырышлары нәтиҗәләре буенча бирелгән Ведомствоара комиссия рәисе күрсәтмәләрен үтәүне оештыра;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы халкына ведомствоара комиссия функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, мәгариф оешмалары вәкилләре (килешү буенча) керергә мөмкин.

4.4. Ведомствоара комиссия составына элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ресоциальләштерү, социаль адаптация һәм социаль тернәкләндерү буенча уңай тәҗрибәгә ия затлар кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы прокуратурасы вәкиле катнашырга хокуклы (килешү буенча).

4.6. Ведомствоара комиссия утырышларына ведомствоара комиссия составына кермәгән дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.7. Комиссия эшендә катнашу җәмәгать башлангычларында башкарыла.

## V. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә алып барыла.

5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализацияләүгә, социаль адаптацияләүгә һәм социаль реабилитацияләүгә ярдәм күрсәтү турында гаризалар кергән саен үткәрелә, әмма кварталга бер тапкырдан да сирәгрәк түгел. Кирәк булган очракта, ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук ведомствоара комиссия әгъзасы инициативасы буенча (рәис белән килештереп һәм ведомствоара комиссия секретаре тәкъдиме буенча) ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия утырышларын ведомствоара комиссия рәисе алып бара, ә ул булмаганда яисә аның кушуы буенча - ведомствоара комиссия рәисе урынбасары.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында яңадан социальләштерүгә, социаль адаптациягә һәм социаль реабилитациягә ярдәм күрсәтү турында гариза керткән затларга, аларның туганнарына, утырышларда катнашулары максатка ярашлы дип танылган башка затларга утырыш көненә кадәр бер тәүлек кала вакыттан да соңга калмыйча хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышы, анда аның составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

5.6. Ведомствоара комиссия карарлары тәкъдим итү характерында була һәм ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

5.7. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия булалар.

5.8. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затның теләге буенча утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча уздырыла.

5.9. Ведомствоара комиссия әгъзалары комиссия утырышында каралган мәсьәләләр турындагы белешмәләрне күрсәтелгән мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратырга хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматларны тараткан өчен ведомствоара комиссия әгъзалары закон нигезендә җаваплы.

5.10. Ведомствоара комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында, ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, массакүләм мәгълүмат чараларына тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.